**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Бишек җырлары**

**1.Нәрсә ул бишек җыры?**

а) бала тирбәткәндә җырлана торган җыр;

ә) лиро-эпик жанрларның берсе, текст шигъри формада була, телдән әйтелә яки көйләп башкарыла;

б) ахыры көтелмәгән характерда булган, кыска, көлкеле хикәя.

**2. Дәреслектән нинди бишек җырлары укыдыгыз?**

а) халык җырларын, Илдар Юзеевның «Дуэт»ын, Эльмира Шәрифуллинаның «Бишек җыры»н, Разил Вәлиевнең «Бишек җыры»н;

ә) Муса Җәлилнең «Кызыма» шигырен;

б) Дәрдемәнднең «Бәллү»ен.

**3. Разил Вәлиевнең «Бишек җыры»на кайсы композитор көй язган?**

а) Шамил Тимербулатов;

ә) Арслан Батыршин;

б) Җәүдәт Фәйзи.

**4. Разил Вәлиевнең «Бишек җыры»нда нинди сүзләр кабатланып килә?**

а) әлли-бәлли, йоклый инде;

ә) йокла, балам, йом күзең;

б) кыйгач кашым, асыл ташым.

**5. Бишек җырларын өйрәнү кирәкме?**

а) әйе;

ә) юк;

б) хәзерге заман өчен кирәкми.

**6. Бишек җырын иң башлап кем җырларга тиеш?**

а) әни;

ә) әти;

б) әби, әни, әти.

**7. «Әлли-бәлли итәр бу, Йокыларга китәр бу». Бу шигъри юлларны кем язган?**

а) халык;

ә) Илдар Юзеев;

б) Эльмира Шәрифуллина.

**8.Разил Вәлиев бишек җырында кемнәрне йоклата?**

а) бәбиләр, әбиләр, малайлар, бабайларны;

ә) бәбиләр, нәниләр, әниләрне;

б) песиләрне, бәтиләрне.

**9.Сез укыган бишек җырларында нинди ягымлы, сүзләр очрады?**

а) балам, карлыгачым, былбылым, багалмам, нәнием, алтын алмам;

ә) сандугачым, былбылым;

б) балам, багалмам, улым.

**Ачкыч**

1. A
2. A
3. A
4. A
5. A
6. A
7. A
8. A
9. A

# Бәяләү

**8-9 балл – “5”ле**

**6-7 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**